| | | |
|---|---|---|
| **ТАТАРСТАН Республикасы**<br>**Аксубай**<br>**муниципальрайоны**<br>**муниципаль беремлеге**<br>**ИСКЕ ИЛДЕРЕК АВЫЛЫ** | | **Республика ТАТАРСТАН**<br>**Аксубаевский**<br>**муниципальный район**<br>**муниципальное образование**<br>**село Старое Ильдеряково** |

**Совет Староильдеряковского сельского поселения**

**Сч. №40204810000000230012 к\сч.30101810000000000805 ИНН-1603000718 БИК 049205805**
**КПП-160301001 ОКПО- 94318576 ОАО «Ак Барс» Банк р.п.Аксубаево ЛБ 039140011 Ст Ил СП**
**Тел.: 4-47-30**

---

# КАРАР

**Иске Илтерәк авыл җирлеге составына керүче Яңа Илтерәк авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

2021 ел, 18 ноябрь №4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Иске Илтерәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илтерәк авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илтерәк авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 05.11.2019 ел, 111 номерлы карары нигезендә, 2021 елның 18 ноябрендә Аксубай муниципаль районының Яңа Илтерәк авыл җирлегендә узган халык җыены нәтиҗәләре буенча халык җыены сорау буенча беркетмә төзелде: «Аксубай муниципаль районы Яңа Илтерәк авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган торучыдан, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 2022 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән сез риза буласызмы?

**1) Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

- вак таш капламалы поселок эчендәге юлларын чокырлы ремонтлау (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- кышкы чорда юлларны карап тоту (кышкы чорда юлларны кардан чистарту-килешү буенча эшләр өчен түләү).

**2) Әлеге кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**

- җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запчастьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

**3) КККны җыю (шул исәптән аерым җыю) һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнашу:**
- контейнерлар сатып алу, контейнер киртәләр төзү (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

**4) Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә:**
- Яңа Илтерәк авылында су үткәргеч челтәрләрен ремонтлау, суэтем башнясын койма белән әйләндереп алу (материаллар сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)).

**5) Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү** (янгын сүндергечләрне, электр белән тәэмин итү челтәренә тоташтырылган яктылык күрсәткечләре сатып алу)

« РИЗА » «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 115 граждан,
тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 60 граждан кертелгән.
Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
« РИЗА» позиция өчен 60 граждан тавыш бирде;
«КАРШЫ» позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены

ХӘЛ ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Яңа Илтерәк авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләре – дөрес дип танырга.

2. Мәсьәлә буенча карар кабул итәргә: «Аксубай муниципаль районы Яңа Илтерәк авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган торучыдан, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 2022 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән **сез риза буласызмы?**

**1) Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**
- вак таш капламалы поселок эчендәге юлларын чокырлы ремонтлау (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- кышкы чорда юлларны карап тоту (кышкы чорда юлларны кардан чистарту-килешү буенча эшләр өчен түләү).

**2) Әлеге кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**
- җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запчастьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

**3) КККны җыю (шул исәптән аерым җыю) һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнашу:**
- контейнерлар сатып алу, контейнер киртәләр төзү (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

**4) Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә:**

- Яңа Илтерәк авылында су үткәргеч челтәрләрен ремонтлау, суэтем башнясын койма белән әйләндереп алу (материаллар сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)).

**5) Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин иту** (янгын сүндергечләрне, электр белән тәэмин итү челтәренә тоташтырылган яктылык күрсәткечләре сатып алу)

3. Иске Илтерәк авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында әлеге карарны халыкка җиткерергә һәм Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aksubaevo.tatar.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

ТР Аксубай муниципаль районы
Иске Илтерәк авыл җирлеге башлыгы: С. М. Маклаков